ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Зеленодольск шәһәре **КАРАР**

**19.10.2021** **№2568**

Зеленодольск муниципаль районы башкарма комитетының 2015 елның 05 мартындагы 477 номерлы карары белән расланган «2015-2023 елларга Зеленодольск муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

Зеленодольск муниципаль районында коррупциягә каршы тору системасын камилләштерү максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1.Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 05 мартындагы «2015-2023 елларга Зеленодольск муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасын раслау турында» 477 номерлы карары белән расланган, «2015-2023 елларга Зеленодольск муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасына (Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 30.05.2016 ел №1432, 06.08.2018 ел №1603 , 01.10.2018 ел №1936, 30.07.2019 ел № 1587 , 12.09.2019 ел №1856 , 26.02.2020 ел №347 , 27.07.2020 ел №1374 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән (алга таба-Программа)түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1.исемендә һәм резолютив өлешендә «2015-2023» цифрларын «2015-2024» цифрларына алмаштырырга;

1.2. "2015-2023 елларга Зеленодольск муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасында (алга таба – Программа), әлеге карар белән расланган:

1.2.1. исемендә «2015-2023» цифрларын «2015-2024» цифрларына алмаштырырга;

1.2.2. Программа паспортында:

- «Программа исеме» юлында «2015-2023» цифрларын «2015-2024» цифрларына алмаштырырга;

– «Программаны гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары» юлында «2015-2023» цифрларын «2015-2024» цифрларына алмаштырырга;

- «Программаны финанслау (чыганак һәм күләмнәр)» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| Программаны финанслау (күләме һәм | Финанслау чыганаклары | Программаны тормышка ашыру еллары | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | Тормышка ашыру |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| чыганаклары) | | | | | | | чорында барлыгы |
| | Муниципаль бюджет (мең сум) | 0 | 238,8 | 238,8 | 238,8 | 238,8 | 955,2 |
| | Федераль бюджет (мең сум)) | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| | Республика бюджеты (мең сум) | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| | Башка чыганаклар | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| | Барлыгы | 0 | 238,8 | 238,8 | 238,8 | 238,8 | 955,2 |

- беренче абзацта «Программа максатларын һәм бурычларын (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) гамәлгә ашыруның көтелә торган ахыргы нәтиҗәләре һәм Программаның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» юлларында «2023 ел ахырына» сүзләрен «2024 ел ахырына» сүзләренә алмаштырырга;

1.2.3. Программаның II бүлегенең икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Әлеге Программа «2015-2024 елларга Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру» дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 19 июлендәге 512 номерлы карарын исәпкә алып, «Татарстан Республикасында коррупциягә каршы көрәш турында» 2006 елның 4 маендагы 34-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 9 статьясын үтәү йөзеннән эшләнде» (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 03.10.2015 № 741, 20.02.2016 № 104, 26.05.2016 № 354, 09.11.2016 № 832, 26.05.2017 № 311, 26.03.2018 № 174, 10.09.2018 №763, 17.06.2019 №495, 16.09 2019 №837, 25.12.2019 №1201, 01.06.2020 г. № 451, 09.09.2020 № 814, 25.03.2021 № 169, 21.06.2021 № 485, 18.09.2021 №880 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән)»;

1.2.4. Программаның II бүлегенең егерме тугызынчы абзацында «2015-2023» цифрларын «2015-2024» цифрларына алмаштырырга;

1.2.5. Программаның V бүлегенең бер, ике, сигез абзацларында «2023 елга» сүзләрен «2024 елга» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. «2015-2023 елларга Зеленодольск муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасының максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм программа чаралары буенча финанслауны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге башлыгына әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында ( http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга .

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче И. Р. Ганиев